**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422727, Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Большие Ковали, ул.Клубная, д.8, оф.1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422727, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Олы Битаман авылы, Клуб ур.,8 йорт, 1 оф

Тел./факс: +7(84365) 74-7-90, e-mail:Bkoval.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19 февраль 2024 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 23.01.2024 № 46 карары белән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ**:

1. 2024 елның 01 мартыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 8370 сум 20 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 1 мартыннан «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 14.04.2021 №7 карары үз көчен югалткан дип танылсын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http//vysokaya-gora. tatarstan. ru.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы
Олы Кавал авыл җирлеге А.И.Файзрахманов

Кушымта N 1
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Олы Кавал авыл
җирлеге башкарма комитетының
19.02.2024 № 1 карарына

2024 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәтнең бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5542,3 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка ташу | 669,31 |
| 4. Кабер (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| Барлыгы | 8370,2 |

Кушымта N2
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитетының 19.02.2024 №1 карарына

2024 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәтнең бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне юу | 301,18 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5241,12 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка ташу | 669,31 |
| 5. Кабер (кабер казу һәм күмү) | 2158,59 |
| Барлыгы | 8370,2 |